КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 8 сентябрь г.Казань № б-2004

Татарстан Республикасында массакүләм физкультура-савыктыру хәрәкәтен популярлаштыру, халыкны актив ял итүгә, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү максатларында:

1. 2023 елның 16 сентябрендә Татарстан Республикасында «Татарстан кроссы – 2023» республика массакүләм ярышларын уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына:

2023 елның 16 сентябрендә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкның төрле яшьтәге катламнарын массакүләм җәлеп итеп, «Милләт кроссы» бөтенроссия йөгерү көнен әзерләү һәм уздыру эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән берлектә, ярышларда катнашу өчен төрле яшьтәге халык катламнарын киң җәлеп итеп, «Татарстан кроссы – 2023» республика массакүләм ярышларын үткәрүне оештырырга.

3. Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, төрле милек формаларындагы предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә әлеге ярышларда үз хезмәткәрләренең катнашуын оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына әлеге ярышларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда хокук тәртибен саклауны һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүне;

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә әлеге ярышлар үткәрелә торган урыннарда санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү максатларында тиешле чаралар оештыруны.

6. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин